# THE HERO ON GUARD OF LANGUAGE (MARKING THE 80TH ANNIVERSARY OF I.ABDULLIN)

**Aynur Akhatovich Timerkhanov,**
The Institute of Language, Literature and Art named after G.Ibragimov,
Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan,
2/31Lobachevskiy Str., Kazan, 420111, Russia,
timtako22@mail.ru.



**ABDULLIN ISKANDAR ABDULLOVICH** (1935-1992) was a linguist and candidate of Philology (1990). After graduating from the Kazan State Pedagogical Institute (1956) he worked as a teacher in the Chelyabinsk region (1956-1959). In 1962, he completed his postgraduate study at the Institute of Language, Literature and History at the Kazan branch of the Academy of Sciences of the USSR, where he later worked as a junior researcher (1962-1986), and from 1986 as a senior researcher.

His scientific works are devoted to the history and stylistics of the literary Tatar language, lexicography and terminology; research into the written Qypchaq monuments in Armenian script, studies of the language of pre-revolutionary journalism, etc. He is the author of five books and more than 120 scientific articles, and co-author of Russian-Tatar dictionaries.

**АБДУЛЛИН ИСКӘНДӘР ГАБДУЛЛА улы** (1935-1992) − тел галиме, филология фәннәре кандидаты (1990). Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлагач (1956), Чиләбе өлкәсендә укытучы (1956-1959). 1962дә СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантураны тәмамлый, анда кече фәнни хезмәткәр (1962-1986), 1986дан өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли.

Гыйльми хезмәтләре татар әдәби тел тарихы һәм стилистикасына, лексикография һәм терминологиясенә, әрмән графикасында язылган кыпчак язма истәлекләрен тикшерүгә, революциягә кадәрге татар публицистикасы телен өйрәнүгә һ.б. багышланган. 5 китап һәм 120дән артык фәнни мәкалә авторы, төрле сүзлекләр автордашы.

**АБДУЛЛИН ИСКАНДАР АБДУЛЛОВИЧ** (1935-1992) − языковед, кандидат филологических наук (1990). После окончания Казанского государственного педагогического института (1956) работал школьным учителем в Челябинской области (1956-1959). В 1962 закончил аспирантуру в Институте языка, литературы и истории Казанского филиала АН СССР, затем работал там же младшим научным сотрудником (1962-1986), с 1986 – старшим научным сотрудником.

Научное труды посвящены истории и стилистике литературного татарского языка, лексикографии и терминологии, исследованиям кыпчакских письменных памятников в армянской графике, изучению языка дореволюционной публицистики и др. Автор 5 книг и более 120 научных статей, создатель русско-татарских словарей (в соавторстве с другими учеными).

Iskandar Abdullin was born into the family of an office employee on October 22, 1935, in Oly Kulbash village of the Zelenodolsk district. He studied in the elementary school in the village of Jake. In 1952, he graduated from the neighbouring village high school with excellent marks.

Later, he went to the city, wanting to get a university education. Having completed his course at

the Kazan State Pedagogical Institute in 1956, I.Abdullin began his teaching career. For three years, he taught the Tatar language and literature, the Russian language and literature and history in the high schools of Parizh and Karabolak villages of the Nagaybek and Kunashak districts in the Chelyabinsk region. For thirty years, his life of a scientist was connected with the Institute of Language, Literature and Art.

In 1959-1962, he completed his postgraduate course at the language department of the Institute of Language, Literature and History named after G.Ibragimov. L.Jalay was appointed his research supervisor. Although his Ph.D. thesis on "The Language of G.Kamal's Drama Pieces" was ready, the young scientist did not present it for certain reasons.

In 1968, I.Abdullin's monograph on "The Language of G.Kamal's Drama Pieces", which had been prepared as a Ph.D. thesis, was published and it made an important contribution to the Tatar literary language studies [1: 198]. Under the guidance of the great turcologist, E.Tenishev, he took a new topic for his Ph.D. thesis: "Linguo-Textologic Research into Pre-Revolutionary Tatar Leniniana", which was only presented in 1990 [2: 16] and is well-known in his homeland and abroad. His scientific research is highly appreciated by the public and scientific community.

In 1962-1986, I. Abdullin worked as a junior researcher at the Institute of Language, Literature and History, and from 1986 to his death (22$^{nd}$ October 1992), he was a senior researcher.

I.Abdullin is the author of five books and more than 120 scientific articles. He also participated in compiling dictionaries. The total number of his works is over two hundred and twenty printer's sheets.

The range of his scientific work was quite wide: the history of the literary language and stylistics, the language of fiction, lexicology and terminology, lexicography, language and textual criticism of the written heritage, epigraphics, the issues of interrelation of the Tatar language with other languages, genealogy issues, reviews of publications, the promotion of the Tatar language and linguist-scientists, etc. A short review of I.Abdullin's scientific research and unpublished works in his personal archive has enabled us to define his contributions to the development of Turkic-Tatar linguistics.

The history of language is one of the areas of linguistic research, which requires a thorough knowledge of the subject as it means working with archives, the written heritage and historical sources. I.Abdullin plunged into continuous research on memorable manuscripts, printed sources and books with centuries-old secrets: it was the meaning of his life.

The scientist conducted a detailed analysis of the works by K.Nasyri, N.Katanov, G.Kamal, G.Kylakhmetov, V.Khakov and others. He explored the research results achieved by the authors and made an attempt to develop their ideas. Now, we turn to I.Abdullin's big article "The Main Concept of Studying the History of Literary Language and Its Sources". In his article, the author, in accordance with his principles, enumerates the requirements for studying the history of the literary language, the issue which is still relevant today.

I.Abdullin devoted several articles to the issues related to historical lexicology and terminology. He achieved important scientific results by investigating synchronically and diachronically the terms of social, political and economic and other spheres. Although he had plans for further research in this area, they were not realized. In this article, we have often referred to the works, which the scholar did not complete.

I.Abdullin studied the interrelations and interactions of languages. For example, his article "Issues of Chronology of Loanwords from Russian and Western European Languages" raises important linguistic issues, which are solved through scientific research.

Undoubtedly, a considerable part of his research work was connected with compiling dictionaries. I.Abdullin was one of the authors who made great contributions to the creation of the three-volume dictionary "Explanatory Dictionary of the Tatar Language" printed in 1977-1981. In 1963-1970, the volume of the scientist's work in lexicography exceeded sixty printer's sheets. His parts of the dictionary are evidence of the author's erudition and his great scientific baggage. In addition, I.Abdullin worked long on the "Tatar-Russian Dictionary" and the "Tatar Educational Dictionary". Bilingual dictionaries published later, were based on these lexicographic works.

I.Abdullin was interested both in linguistics, literature and folklore as well as history. For example, he studied genealogy and proved the kinship of Tatar and Russian writers, A.Eniki and A.Kuprin. These findings were published in the collection of articles "Searches, Thoughts, Discoveries". The hand-written autobiography of Kh.Yamashev, presented to readers, was the result of the author's long work in the archives. He found

new materials about G.Kolakhmetov and aggregated them for the use of the scientific community. I.Abdullin prepared the collection "Selected Works" for the centenary of this writer, publicist and public figure. Thus, for many years, he worked in the field of Tatar literature and textual criticism.

Of special interest are the scientist's thoughts about our literary heritage. The article, prepared by him in 1980 and published only in 2006, analyses the interrelation of the Turkish-Tatar literatures and literary languages. Here, using a wealth of factual material, the author reveals the elements of Turkish culture and literature that had a positive impact on Tatar theatre, the genre system of Tatar literature and on the education of the Tatar people in general.

I.Abdullin focuses on the interrelation between the language and the literary process, which was growing and changing. It is known that at the turn of the twentieth century, society discussed the issue of how simple the Tatar language was to be. As examples, classical Arab, or Ottoman Turkish, or any other literary language, similar to the national spoken language, were given. This dispute found its reflection in Tatar and Turkish printed editions. Having studied all the works on the topic, I.Abdullin specifies the place and the role of Tatar educators, participating in the dispute and emphasises the correctness of their choice, concerning the future of the Tatar language.

I.Abdullin was responsible for different important activities of the Soviet Turcologists' Committee: the study of the sources of 1905-1907 (these were leaflets and brochures based on manuscripts, printed with a hectograph method), their systematization, the description of their Tatar translation in terms of textual and linguistic aspects and their preparation for publication. The results of this work were published in Russian, entitled "Descriptions of the Tatar Bolshevik's Publications during the Revolution of 1905-1906". About 250 translated texts were analysed, familiarising us with the ideology of those times. Grammatical and lexical features of the texts were described in comparison with the original Russian version and the quality of the translation style was investigated. Part of the work was devoted to the spelling in the written sources, which enables us to discuss Tatar spelling at the beginning of the twentieth century. Based on these studies, I.Abdullin wrote such monographs as "Bolsheviks' Militant Word" and "Linguistic and Textual Studies of Pre-Revolutionary Tatar Leniniana".

On his own initiative, the scholar created the "Corpus of Monuments of the 16$^{th}$ Century Qypchaq Language in the Armenian Script". The results of the work were presented at the meeting of the 12$^{th}$ Plenum of the Committee which was held in Nalchik on May 13, 1986. The chairman of the Committee in 1986-2004, the well-known turcologist, E.R.Tenishev, highly appreciated the work and suggested including it in the research plan of the Institute, however, the work was not published. In our opinion, the importance of the research lies in I.Abdullin's attempt to explore the origin of the Tatar people, their language, culture and history. His works, published in 1970-1980, testify to the fact.

I.Abdullin became interested in Qypchaq texts in the Armenian script after completing his postgraduate studies in 1960. To conduct this work, he learned the Armenian language and went to the Central Archive of History of Ukraine. He also worked at the Institute of Ancient Manuscripts "Matenadaran" in Yerevan. Having examined these sources, he did special research into their relationship with the Qypchaq language. He came to serious conclusions that the language of the sources was close to the Tatar language, especially its western dialect. For the first time, he spoke about his conclusions at the linguistic conference in Kazan in 1966. The same year, I.Abdullin presented the results of his research in Helsinki.

The greater part of the sources comes from the archives of Ukraine. These are numerous handwritten materials, dating back to the 16-17$^{th}$ centuries. They concern the Armenians, who moved from the regions of Aksaray (the Golden Horde) and Kaf (currently Feodosiya) to Ukraine, Romania and Poland in the 14-15$^{th}$ centuries. These are the conclusions, at which the author arrived. According to the researcher, from the 11$^{th}$ century, Armenians lived in close interaction with Dashti-Qypchaqs and Qypchaqs of the Golden Horde, conducted diplomatic relations and were actively engaged in trade and translation activities. Thus, having closely communicated with each other for a long time, Armenians acquired the Qypchaqs' way of life and customs, which influenced their language. Eventually, the Qypchaq language survived in its competition with the Armenian language. Armenians called the language they used *tatarča* "Tatar", *khyfčaxča*, "Qypchaq", or *bizim tel*, "own language". In scientific literature the language of hand-written books of the 16-17$^{th}$ centuries, written in the Armenian script or the old Qypchaq spoken

language, is conditionally called Armenian-Qypchaq.

Unlike the opinion contained in other registered sources, I. Abdullin believed that the Armenian texts of this period were written in the pure Qypchaq language. In this phase, it did not experience the impact of the Slavic, Turkish and other languages. Besides, many materials (protocols of the court, judgements, testimonies of witnesses, receipts, etc.) were written in the vernacular. According to the author, those sources had scientific value for the history of the language. The influence of the language of hand-written sources was investigated based on the Tatar dialects and this opinion was confirmed by a great deal of evidence.

Although many years have passed, the publications of I.Abdullin have not lost their significance in terms of the history of the language. They are especially important for Tatar science, as the researcher studied these sources continuously and thoroughly in the context of the Tatars' ethnogenesis, their language and history. If we publish all the materials collected by the author, this work will be an additional source for the solution of certain issues in Turkish-Tatar linguistics, especially in the history of the language. There also exist interesting facts for historical research.

If I.Abdullin, a great scientist, who made great contributions to Turcology, were still alive, he would be 80 years old now. Today, his noble endeavours are stored inside the Soul of the people. His works have not lost their relevance; they are in subject to active scientific research and promote the preservation and development of our language.

**References**


1. *Abdullin I.A.* G. Kamal dramalarynyŋ tele. Kazan: Tat. kit. näshr., 1968. 198 b. (in Tatar)
2. *Abdullin I.A.* Lingvo-tekstologicheskoe issledovanie dorevolyutsionnoy tatarskoy leniniany: Avtoref. dis. … kand. filol. n. Kazan', 1990. 16 s. (in Russian)
3. *Abdullin I.A.* Ädäbi tel tarikhyn häm chyganaklar öyränüneŋ töp kontseptsiyaläre // Nekotorye itogi i zadachi izucheniya tatarskogo literaturnogo yazyka. Kazan', 1992. B. 8-20. (in Tatar)
4. *Abdullin I.A.* K voprosu o khronologizatsii russkikh i zapadnoevropeyskikh zaimstvovaniy v tatarskom yazyke // Dvuyazychie: tipologiya i funktsionirovanie. Kazan', 1990. S.21-32. (in Russian)
5. Tatarcha-ruscha süzlek. M.: "Sovetskaya entsiklopediya" näshr., 1966. 864 s. (in Tatar)
6. Tatarcha-ruscha süzlek / Töz. I.A.Abdullin, F.A.Ganiev, M.G.Mökhämmädiev, R.A.Yunaleeva. Kazan': Tatar. kit. näshr., 1988. 462 b. (in Tatar)
7. Tatarcha-ruscha uku-ukytu süzlege / F.A. Ganiev, I.A.Abdullin, R.G.Gataullin. M., 1992. 388 b. (in Tatar)
8. *Abdullin I.A.* Aleksandr Kuprin häm Ämirkhan Eniki // Ezlänülär, uylanular, tabyshlar: Žyentyq; töz. A.K.Timergalin. Kazan: Tatar. kit. näshr., 1989. S. 237-248. (in Tatar)
9. *Abdullin I.A.* Turetsko-tatarskie literaturnye i yazykovye svyazi // Problemy leksikologii leksikografii. Vyp. 7. Kazan', 2006. S. 5-36. (in Russian)
10. *Abdullin I.A.* Opisanie pervykh proizvedeniy bol'shevistskoy pechati na tatarskom yazyke perioda revolyutsiy 1905–1907 godov. Kazan': Tat. kn. izd-vo, 1986. 220 s. (in Russian)
11. *Abdullin I.A.* "Pamyatnaya zapiska" Agopa na armyano-kypchakskom yazyke (1620) // Sovetskaya tyurkologiya. 1971. №3. S. 118-129. (in Russian)
12. *Abdullin I.A.* Armyano-kypchakskaya epigrafika // Tezisy dokladov Itogovoy nauchnoy sessii Kazanskogo filiala AN SSSR za 1972 god. Kazan', 1973. S. 48-52. (in Russian)
13. *Abdullin I.A.* Armyano-kypchakskie teksty iz arkhiva F.E.Korsha // Tatar tele häm ädäbiyaty. Kazan, 1976. Kn. 5. Pp. 5–23; *Abdullin I.A.* Protokol ot 17 avgusta 1580 g. // Issledovanie yazyka drevnepis'mennykh pamyatnikov. Kazan', 1980. S. 40-65. (in Russian)
14. *Abdullin I.A.* Armyano-kypchakskie rukopisi i ikh otnoshenie k dialektam tatarskogo yazyka // Materialy po tatarskoy dialektologii. Kazan': Tatar. kn. izd-vo, 1974. S. 166-185. (in Russian)
15. *Ganiev F., Khäyrullin M.* Žirdä anyŋ eze bar // Vatanym Tatarstan. 1995, 24 oktyabr'. (in Tatar)
16. *Garipova F.* Ižat kaharmany // Vatanym Tatarstan. 2000 el, 8 noyabr'. (in Tatar)
17. *Abdullin I.G.* // Tatarskaya entsiklopediya: V 5 t. / Gl. red. M.Kh.Khasanov, otv. red. G.S.Sabirzyanov. T. 1: A–V, Kazan', ITE AN RT, 2002. S. 16 (672 s.). (in Russian)
18. *Abdullin I.G.* // Tatar entsiklopediyase: 6 tomda / Bash mökhärrir M.Kh.Khäsänov, žavaply mökhärrir G.S.Sabiržanov. T. 1: A–V, Kazan, TFA TES, 2008. 16 b. (720 b.). (in Tatar)
19. Abdullin Iskander Abdullovich // Kazanskaya lingvisticheska shkola: Kniga pervaya: Kazanskaya tyurkskaya lingvisticheskaya shkola / Sost. M.Z.Zakiev. Kazan': Tatar. kn. izd-vo, 2008. S. 334-335. (in Russian)

# ТЕЛ САГЫНДА ТОРГАН КАҺАРМАН (ИСКӘНДӘР АБДУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ)

**Айнур Әхәт улы Тимерханов,**
Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе,
Россия, 420111, Казан ш., Лобачевский ур., 2/31 нче йорт,
timtako22@mail.ru.

Искәндәр Абдуллин 1935 елның 22 октябрендә Татарстанның Яшел Үзән районындагы Олы Күлбаш авылында хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә. Олы Җәкедә башлангыч белем ала, 1952 елда күрше авылда урнашкан Карагуҗа урта мәктәбен бик яхшы билгеләренә тәмамлый.

Югары белем алу теләге егетне калага китерә. 1956 елда Казан дәүләт педагогика институтын кызыл дипломга тәмамлап, И.Абдуллин укытучылык эшенә керешә. Өч ел дәвамында Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк һәм Кунашак районнарының Париж һәм Караболак авыллары урта мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, тарих фәннәрен укыта. Галимнең шуннан соңгы тормыш юлы утыз ел дәвамында ТӘҺТИ белән бәйле була.

1959-1962 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының (хәзерге ТӘҺСИ) тел бүлегендә аспирантурада укый. Фәнни җитәкчесе итеп танылган тел галиме Л.Җәләй билгеләнә. «Г.Камал драмаларының теле» дигән темага язылган кандидатлык диссертациясе әзер булса да, яшь галим аны, ни сәбәпледер, якламый кала.

1968 елда И.Абдуллинның кандидатлык диссертациясе сыйфатында әзерләнгән, татар әдәби теле тарихын өйрәнүгә саллы өлеш керткән «Г.Камал драмаларының теле» монографик хезмәте басылып чыга [1: 198]. Күренекле тюрколог Э.Тенишев җитәкчелегендә «Революциягә кадәрге татар ленинианасын лингво-текстологик тикшерү» дигән яңа кандидатлык диссертациясе темасы алып, ул аны күпкә соңрак, 1990 елда яклый [2: 16]. Үз хезмәтләре белән ватанында гына түгел, чит илләрдә дә танылып өлгергән И.Абдуллинның докторлык диссертациясе югарылыгында язылган фәнни хезмәте киң җәмгатьчелек тарафыннан һәм фәнни даирәдә югары бәяләнә.

1962-1986 елларда И.Абдуллин Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында кече фәнни хезмәткәр, 1986 елдан алып 1992 елның 22 октябренә, ягъни вафатына кадәр, өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли.

И.Абдуллин – 5 китап һәм 120дән артык фәнни мәкалә авторы һәм ул сүзлекләр төзүдә катнаша. Хезмәтләренең гомуми күләме 220 басма табактан артып китә.

Галимнең фәнни эшчәнлек диапазоны гаять киң була: әдәби тел тарихы һәм стилистика, матур әдәбият теле, лексикология һәм терминология, лексикография, язма ядкярләр теле һәм текстологиясе, эпиграфика, татар теленең башка телләр белән бәйләнеш проблемалары, шәҗәрә-генеалогия мәсьәләләре, басылып чыккан хезмәтләргә бәяләмәләр язу, татар телен һәм телче галимнәрне пропагандалау һ.б. И.Абдуллинның фәнни эшчәнлеге юнәлешләренә һәм шәхси архивында хәзергә кадәр басылмый яткан хезмәтләренә кыскача күзәтү ясау галимнең төрки-татар тел белемен үстерүгә керткән өлешен билгеләргә ярдәм итә.

Тел гыйлемендә катлаулы, җаваплы, тикшерүчедән һәр өлкәдә мәгълүматлы һәм белемле булуны таләп иткән юнәлешләрнең берсе – тел тарихы. Бу тармакта гыйльми эзләнүләр алып бару иң элек архив материаллары, язма ядкярләр, чыганаклар белән эш итүне күз уңында тота. Күпгасырлык серләрне яшереп саклаган һәртөрле кульъязма истәлек, басма чыганаклар, китап мәгарәсендә туктаусыз казыну И.Абдуллинның тормыш стихиясенә әйләнә.

Галим бу өлкәдә К.Насыйри, Н.Катанов, Г.Камал, Г.Коләхмәтов, В.Хаков һ.б.ларның эшчәнлекләрен тәфсилләп анализлап чыга. Аның нәтиҗәләрен үз хезмәтләрендә чагылдырып кына калмый, ә бу галимнәрнең карашларын үстерергә омтыла. Бу нисбәттән аның «Әдәби тел тарихын һәм чыганаклар өйрәнүнең төп концепцияләре» [3: 8-20] дип аталган күләмле мәкаләсе игътибарга лаек.

Мәкаләдә автор, үз принципларына тугрылык саклаган хәлдә, тел тарихын өйрәнүнең бүген дә актуаль яңгыраган зарури таләпләрен санап чыга.

Тарихи лексикология һәм терминология мәсьәләләрен өйрәнүгә дә И.Абдуллин дистәләгән мәкаләләр багышлый. Иҗтимагый-сәяси, икътисади һ.б. тармакларга караган терминнарны синхрон һәм диахрон планда җентекле һәм эзлекле тикшереп, мөһим фәнни нәтиҗәләр ясый. Бу юнәлештә аның киләчәк планнары булса да, алар тормышка ашмый кала. Мәкаләбездә галим тарафыннан башлап җибәрелеп тә, ахырынача тәмамланмый калган эшләре янә бер кат искәртелә.

И.Абдуллин телләрнең үзара бәйләнешен һәм тәэсирен өйрәнү юнәлешендә күп хезмәт куя. Мәсәлән, «Рус һәм Көнбатыш Европа телләреннән кергән алынмаларны хронологияләү мәсьәләләре» [4: 21-32] мәкаләсендә мөһим проблема күтәреп, аны югары фәнни дәрәҗәдә ача.

Фәнни эшчәнлегенең зур һәм, һичшиксез, игътибарга лаек тармагы сүзлекләр төзү белән бәйле була. И.Абдуллин – 1977-1981 елларда дөнья күргән 3 томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н төзүгә иң саллы өлеш керткән авторларның берсе. 1963-1970 елларда лексикография өлкәсендә галим башкарган хезмәтнең күләме 60 басма табакка якын. Сүзлекнең ул төзегән кисәкләре авторның киң эрудицияле, бай фәнни багажлы булуы турында сөйли. Моннан тыш, И.Абдуллин «Татарча-русча сүзлек» [5: 864; 6: 462], «Татарча-русча уку-укыту сүзлеге» [7: 388] тәрҗемәле сүзлекләрен төзүгә күп вакытын һәм көчен сарыф итә. Соңрак нәшер ителгән ике телле сүзлекләр шушы лексикографик хезмәтләрнең уңай тәҗрибәсенә таянып эшләнә.

И.Абдуллин, тел белеме өлкәсе белән генә чикләнмичә, әдәбият, фольклор, тарих белән дә кызыксына. Мәсәлән ул, нәсел шәҗәрәләрен өйрәнү белән мавыгып китеп, Ә.Еникинең күренекле рус язучысы А.Куприн белән кардәшлеген дәлилли. Бу хакта «Эзләнүләр, уйланулар, табышлар» (1989) җыентыгында бәян ителә [8: 237-248]. Х.Ямашевның үз кулы белән язылган автобиографиясенең укучы игътибарына тәкъдим ителүе дә тынгысыз галимнең архивларда эзләнү нәтиҗәсе булып тора. Ул Г.Коләхмәтов турында яңа архив материаллары табып, аларны эшкәртеп, фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә. Язучы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесенең 100 еллык юбилеена «Сайланма әсәрләр» җыентыгын төзи. Шул рәвешле, озак еллар дәвамында татар әдәбияты белеменең әдәбият чыганаклары белеме һәм текстология тармагына да хезмәт итә.

Галимнең кардәш халыкларның әдәби мирасы, әдәби бәйләнешләр хакындагы уйланулары да кызыклы. 1980 еллар ахырында әзерләнеп, 2006 елда гына басылган күләмле мәкаләсе төрек-татар әдәби һәм тел бәйләнешләрен җентекләп анализлауга багышлана [9: 5-36]. Биредә бай фактик материал һәм чыганаклар нигезендә автор татар театры тарихына, яңа татар әдәбиятының жанрлар системасы үзгәрешенә, гомумән, халыкны агартуга төрек мәдәнияте һәм әдәбиятының уңай тәэсирен яктырта.

И.Абдуллин әдәби процессның тел торышы, аның үсеш-үзгәреше белән турыдан-туры бәйле булуын ассызыклый. Мәгълүм булганча, XIX йөз ахыры – XX гасыр башында гомумаңлаешлы татар теле нинди булырга тиеш дигән сорау тирәсендә кызу бәхәсләр башлана. Мондый тел сыйфатында я классик гарәп теле, я госманлы төрек теле, я халыкның сөйләм теленә якын торган әдәби тел күрсәтелә. Билгеле, бу бәхәс татар, төрек матбугаты битләрендә киң чагылыш таба. Мәкалә авторы, шул вакыйгаларны яктырткан язмаларны янә күз уңыннан үткәреп, бу процесста татар зыялыларының тоткан урынын һәм ролен билгели һәм татар теленең язмышын хәл итүдә, ялгыш юлга тайпылмыйча, аларның дөрес юнәлеш сайлаганлыгын ассызыклый.

И.Абдуллин Совет тюркологлары комитеты белән дә хезмәттәшлек итә, төрле җаваплы эшләр башкара. 1905-1907 елларга караган чыганакларны – кульъязма текстлар нигезендә гектография ысулы белән басылган листовка һәм брошюраларны барлау, системага салу, аларның татарчага тәрҗемәләрен текстологик һәм лингвистик аспектта тасвирлау һәм басмага әзерләү әнә шуларның бер өлеше була. Хезмәт «1905-1906 еллар революциясе чорындагы татарча большевистик матбугат әсәрләренең тасвирламасы» исеме белән рус телендә нәшер ителә [10: 220]. Биредә шул чор идеологиясен чагылдырган 250ләп берәмлек тәрҗемә текст киң лингвистик яссылыкта анализлана. Текстларның, русча оригиналлары белән чагыштырылып, грамматик һәм лексик үзенчәлекләре тасвирлана, стильгә бәйле сыйфатлары ачыклана. Бер өлеше кульъязма шәкелендә булган чыганакларның

орфографиясенә дә зур игътибар бирелә, шуның нигезендә XX йөз башы татар орфографиясенең торышын күзаллау мөмкинлеге туа. Шушы юнәлештә галимнең «Большевистик сугышчан сүз» (1987) һәм «Революциягә кадәрге татар ленинианасын лингво-текстологик тикшерү» монографик хезмәтләре дөнья күрә.

И.Абдуллинның үз теләге белән алынып эшләгән икенче зур темасы «Әрмән язулы XVI гасыр кыпчак теле ядкярләре корпусы» дип атала. Эш нәтиҗәләре 1986 елның 13 маенда Комитетның Нальчикта узган XII Пленумы утырышында тикшерелә һәм басмага тәкъдим ителә. Комитетның 1986-2004 еллардагы председателе дөньякүләм танылган тюрколог Э.Р.Тенишев, хезмәткә югары бәя биреп, аны Институт эш планына кертергә тәкъдим итсә дә, ул басылмый кала. И.Абдуллин башкарган эш, безнең карашка, авторның чыганакларны өйрәнү-тикшерүгә татар халкы, аның теле, мәдәнияте, тарихы ноктасыннан якын килү омтылышы белән әһәмиятле. Бу хакта галимнең 1970-1980 еллар башында басылган хезмәтләре сөйли [11; 12; 13].

Әрмән язулы кыпчак текстлары белән И.Абдуллин 1960 елларда, аспирантура тәмамлагач ук, шөгыльләнә башлый. Эшне уңышлы башкарып чыгу өчен, ул, әрмән язуын үзлегеннән өйрәнеп, Украинаның Үзәк тарих архивына юл тота. Шул ук вакытта Ереванга барып, борынгы кульъязмалар институты «Матенадаран»да эшләргә өлгерә. Анда сакланган чыганаклар белән танышып, кыпчак теленә мөнәсәбәтлеләрен аерып тикшерә. Чыганаклар теленең татар теленә, аеруча, аның көнбатыш диалектына якынлыгын дәлилләү юнәлешендә җитди нәтиҗәләргә ирешә. Бу хакта И.Абдуллин беренче мәртәбә 1966 елда Казанда үткән лингвистик конференциядә бәян итә, аннары 1969 елда Хельсинки университеты студентлары һәм укытучыларына үткәргән семинарда да тәфсилләп сөйли.

Чыганакларның төп өлеше белән ул Украина архивларында таныша. Сүз XVI-XVII гасырларга караган күпсанлы кульъязма материаллар турында бара. Әлеге материаллар XIV-XV гасырларда Аксарай (Алтын Урда) һәм Каф (хәзерге Феодосия) регионыннан Украина, Румыния һәм Польшага күченгән һәм кыпчаклашкан әрмәннәргә карый. Һәрхәлдә, автор шушындый фикердә тора [14:168]. Галим карашынча, әрмәннәр, XI гасырдан бирле Дәшти-Кыпчак һәм Алтын Урда кыпчаклары белән тыгыз бәйләнештә яшиләр, дипломатик мөнәсәбәтләрне җайга салалар, актив рәвештә сәүдә белән шөгыльләнәләр, тылмачлык итәләр. Шул рәвешле, озак вакытлар тыгыз аралашып яшәү нәтиҗәсендә, әрмәннәр кыпчакларның тормыш итү рәвешен, гореф-гадәтләрен үзләштерәләр. Билгеле, мондый вазгыять тел кулланылышына да үзгәрешләр кертә. Әрмән теле акрынлап кыпчак теле тарафыннан кысрыклап чыгарыла. Кулланылыштагы телне әрмәннәр үзләре tatarča ‘татарча’, xufčaxča ‘кыпчакча’ яки bizim tel ‘безнең тел’ дип атаганнар. Фәнни әдәбиятта әрмән графикасына нигезләнеп язылган XVI-XVII гасыр кульъязма китаплар теле – иске кыпчак сөйләм теле – шартлы нигездә әрмән-кыпчак теле дип йөртелә, ә кульъязма китаплар исә фәнни әйләнешкә әрмән-кыпчак чыганаклары дип кереп киткән [14: 169].

Соңрак теркәлгән чыганаклардан аермалы буларак, И.Абдуллинның күзәтүләренә караганда, әлеге чор әрмән язулы текстлар чагыштырмача чиста кыпчак телендә башкарылган. Монда славян, төрек һәм башка телләрнең йогынтысы бу этапта әлегә сизелми. Өстәвенә, күп кенә материаллар (судта сорау алу беркетмәләре, суд карарлары, шаһитләрнең күрсәтмәләре, распискалар һ.б.) җанлы сөйләм теле үрнәкләрен чагылдыра. Нәкъ менә шушы ягы белән чыганаклар тел тарихы өчен аеруча фәнни әһәмияткә ия дигән фикер әйтә автор [14: 166-185]. Ул язмада чыганаклар теленең татар диалектларына мөнәсәбәте тикшерелә һәм бу караш күп дәлилләр белән раслана.

Шактый еллар үтүгә карамастан, галимнең басылмый калган материаллары тел тарихы күзлегеннән бүген дә фәнни кыйммәтен югалтмаган. Алар татар халкы этногенезы, аның теле, тарихы ноктасыннан эзлекле һәм фәнни нигездә өйрәнелгәнлектән, татар фәне өчен аеруча әһәмиятле. Галим җыеп, теркәп, беренчел шәкелдә тасвирлап өлгергән материалларны текстологик яктан тиешле югарылыкта басмага әзерләп, булган факсимилеләре белән бергә бастырып чыгарган мәлдә, бу хезмәт төрки-татар тел белеменең аерым мәсьәләләрен, бигрәк тә тел тарихына кагылышлыларын, хәл итүдә өстәмә чыганак була алыр иде. Тарихчылар өчен дә бу чыганакларда кызыклы фактлар табылырга мөмкин.

Тюркологиянең күп тармакларында җуелмас эз калдырган олы галим Искәндәр Абдуллинга, исән булса, 80 яшь тулган булыр

иде. Анын кылган игелекле гамәлләре бүген дә халык күңелендә саклана [15-19]. Галимнең хезмәтләре хәзер дә актуальлеген югалтмыйча, актив фәнни әйләнештә, хәрәкәттә, телебезне саклауга һәм үстерүгә булышлык итә.

**Әдәбият**


1. *Абдуллин И.А.* Г. Камал драмаларының теле. Казан: Тат. кит. нәшр., 1968. 198 б.
2. *Абдуллин И.А.* Лингво-текстологическое исследование дореволюционной татарской ленинианы: Автореф. дис. ... канд. филол. н. Казань, 1990. 16 с.
3. *Абдуллин И.А.* Әдәби тел тарихын һәм чыганаклар өйрәнүнең төп концепцияләре // Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка. Казань, 1992. С. 8-20.
4. *Абдуллин И.А.* К вопросу о хронологизации русских и западноевропейских заимствований в татарском языке // Двуязычие: типология и функционирование. Казань, 1990. С.21-32.
5. Татарча-русча сүзлек. М.: «Советская энциклопедия» нәшр., 1966. 864 б.
6. Татарча-русча сүзлек / Төз. И.А.Абдуллин, Ф.А.Ганиев, М.Г.Мөхәммәдиев, Р.А.Юналеева. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 462 б.
7. Татарча-русча уку-укыту сүзлеге / Ф.А.Ганиев, И.А.Абдуллин, Р.Г.Гатауллин. М., 1992. 388 б.
8. *Абдуллин И.А.* Александр Куприн һәм Әмирхан Еники // Эзләнүләр, уйланулар, табышлар: Җыентык; төз. А.К.Тимергалин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 237-248 бб.
9. *Абдуллин И.А.* Турецко-татарские литературные и языковые связи // Проблемы лексикологии лексикографии. Вып. 7. Казань, 2006. С. 5-36.
10. *Абдуллин И.А.* Описание первых произведений большевистской печати на татарском языке периода революций 1905–1907 годов. Казань: Тат. кн. изд-во, 1986. 220 с.
11. *Абдуллин И.А.* «Памятная записка» Агопа на армяно-кыпчакском языке (1620) // Советская тюркология. 1971. №3.С. 118-129.
12. *Абдуллин И.А.* Армяно-кыпчакская эпиграфика // Тезисы докладов Итоговой научной сессии Казанского филиала АН СССР за 1972 год. Казань, 1973. С. 48-52.
13. *Абдуллин И.А.* Армяно-кыпчакские тексты из архива Ф.Е.Корша // Татар теле һәм әдәбияты. Казан, 1976. Кн. 5. С. 5–23; *Абдуллин И.А.* Протокол от 17 августа 1580 г. // Исследование языка древнеписьменных памятников. Казань, 1980. С. 40-65.
14. *Абдуллин И.А.* Армяно-кыпчакские рукописи и их отношение к диалектам татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. С. 166-185.
15. *Ганиев Ф., Хәйруллин М.* Җирдә анын эзе бар // Ватаным Татарстан. 1995, 24 октябрь.
16. *Гарипова Ф.* Иҗат каһарманы // Ватаным Татарстан. 2000, 8 ноябрь.
17. *Абдуллин И.Г.* // Татарская энциклопедия: В 5 т. / Гл. ред. М.Х.Хасанов, отв. ред. Г.С.Сабирзянов. Т. 1: А–В, Казань, ИТЭ АН РТ, 2002. С. 16 (672 с.).
18. *Абдуллин И.Г.* // Татар энциклопедиясе: 6 томда / Баш мөхәррир М.Х.Хәсәнов, җаваплы мөхәррир Г.С.Сабирҗанов. Т. 1: А–В, Казан, ТФА ТЭС, 2008. 16 б. (720 б.).
19. Абдуллин Искандер Абдуллович // Казанская лингвистическа школа: Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа / Сост. М.З.Закиев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. С. 334-335.